**Межрегиональные предметные олимпиады КФУ**
**профиль «Татарский язык»**
**ОТВЕТЫ заданий заключительного этапа**
**2025-2026 учебный год**
**8-9 классы**

**I. Кыш башлану белән исә бер үк төрле көндәлек тормышта күптән көтелгән үзгәрешләр башланачак инде** (Н.Фәттах “Сызгыра торган уклар”) җөмләсендә ничә сонор тартык бар? Кабатланган тартыкларны да санарга / Сколько сонорных звуков в данном предложении (повторяющиеся звуки тоже считать) *(10 баллов).*

**Җавап:** 20 (**Кыш башлану белән исә бер үк төрле көндәлек тормышта күптән көтелгән үзгәрешләр башланачак инде)**

**II. Тексттан фразеологизмнарны табыгыз, мәгънәләрен аңлатыгыз.** ***Әле дә булса биш намазга йөргән Нисбах картны һич кенә дә туксаннан өстә димәссең: җилле йөри, җор телле, сүз эзләп кесәгә керми. Нисбах картны аяклы тарих дип тә әйткәлиләр*** **(М.Хәбибуллин) /** Найдите в тексте фразеологизмы и объясните значение. *(10 баллов. За каждый правильный ответ по 2 балла).*

**Җавап:**

Туксаннан өстә – туксан яшьтән узган.

Җилле йөри – тиз йөри.

Җор телле – шук, шаян телле.

Сүз эзләп кесәгә керми – сүзгә, җавапка аптырамый

Аяклы тарих – күпне белә.

**III. Түбәндәге сүзләрнең омонимик мәгънәләрен табыгыз:** АЙ, БАР, КҮК, ТАБА, ЯШЬ / Найдите омонимичные значений данных слов *(15 баллов. За каждый правильный ответ – 3 балла).*

**Җавап:** АЙ – месяц, междометие, луна; БАР – есть, иди, бар (кафе); КҮК – небо, синий, как будто; ТАБА – сковорода, послелог, находит (глагол); ЯШЬ – молодой, возраст, слеза

**IV. Рус телендәге рәвешләрнең татарча эквивалентларын табыгыз. Тәрҗемә иткәндә барлык очракларда да рәвеш барлыкка киләме? /** Найдите татарские эквиваленты русских наречий. Получается ли в переводе во всех случаях наречие? *(10 баллов. За каждый правильный ответ по 1 баллу)*

*Внезапно, недавно, наоборот, снова, заново, помаленьку, невыгодно, смолоду, настежь, наотрез*

**Җаваплар:** Кинәт, күптән түгел, киресенчә, яңадан, өр-яңадан, әкренләп, отышлы түгел, яшьләй, каерып ачып, кистереп.

**V. Бирелгән сүзләрдән парлы сүзләр ясагыз, терәк сүзләрдән файдаланыгыз. Терәк сүзләр арасында артык сүзләр булуын онытмагыз! /** Образуйте от данных слов парные слова. Используйте опорные слова, не забудьте: среди них есть лишние слова. *(10 баллов. За каждый правильный ответ по 1 баллу)*

**Җавап:** сирәк-мирәк, иртә-кич, биек-биек, аң-белем, күзгә-күз, бала-чага, уен-көлке, көн-төн, аз-маз, йокылы-уяулы.

**VI. Бирелгән тексттан а) МИН алмашлыгының килеш формаларын табыгыз һәм МИН алмашлыгы кергән җөмләләрнең номерларын татар телендәге килешләр тәртибенә туры китереп тезегез. Мәсәлән: 3, 6, 2.... б) Кайсы килеш формасы юк? Ул ничек булырга тиеш? МИН алмашлыгын шул килештә кулланып, җөмлә төзеп языгыз. /** Найдите в тексте падежные формы местоимения МИН и расположите номера предложений с местоимением МИН по порядку падежей татарского языка. Например, 3, 6, 2... Какой падеж не встречается? Напишите предложение, употребляя МИН в отсутствующей форме. *(10 баллов. За первую часть вопроса 5 баллов; за вторую часть – 5 баллов.)*

(1) Әйе, бу минем ундүрт яшьлек чагым. (2) Мин гел нидер көтеп яшим. (3) Хыялым бары киләчәктә генә... (4) Киләчәк мине дәшә, чакыра, әллә ниләр вәгъдә итә, ләкин беләм, бу әле якты, томанлы рәшә генә, аңа әле барып җитәсе бар... (5) Нәрсә ачылыр ул томан артында – миңа билгесез. (6) Менә шушы

билгесезлек гел борчып, үртәп, җанымны ничектер ләззәтле сыкратып тора да шикелле... (7) Күңелдә эледән-эле өмет белән өметсезлек чиратлашып туа, вакыт-вакыт үземне, кешеләрне, җирдәге бөтен җан иясен өзелеп кызгана башлыйм, берәүгә дә афәт килә күрмәсен иде, берәү дә бу якты дөньядан мәхрүм булмасын иде дип тели-ялвара башлыйм. (8) Ләкин шуның артыннан ук миндә искиткеч бер көч, дәрт, өмет кабына ки, бөтен дөньяны ал да гөл итеп, бөтен кешеләрне тигез, шат, бәхетле итеп, үземне исә бәхетнең җиде кат күгендә итеп күрә башлыйм. (Ә.Еники “Җиз кыңгырау” әсәре буенча)

**Җавап: 2, 1, 5, 4, 8. Чыгыш килеш формасы кулланылмаган. Җөмлә: Сеңелем МИННӘН кайда укуымны сорады.**

**VII. Туры сөйләм янындагы тыныш билгеләрен куегыз. /** Ставьте знаки препинания при прямой речи. *(15 баллов).*

**Җавап:**

Кайвакыт суны күрше коедан алам да, чишмәдән китердем дип хәйләлим. Буламы соң! Әти иренен тидерү белән үк сизеп ала.

– Нинди судан куйдыгыз самаварны? – дип сорый.

– Чишмә суы белән, – ди әни, мин әйткәнчә.

– Кил әле, эчеп кара әле.

Әни татып карый да:

– Әллә инде тагын. Сукыр тавыкка бар да ярма. Су су инде, – ди.

– Мин үзебезнең чишмә суын дөньядагы бернинди су белән дә алыштырмыйм. Ә сез, экәмәтләр, тәмен дә аермыйсыз...

Аннары чәшкәсен читкә этәреп, ачусыз гына:

– Малай, тагын бер тапкыр алдашсаң, матри, – дип куя.

«Су булгач, барыбер түгелме икәнни. Әти аның тәмен ничек аера икән?» дип шакката идем.

Инде хәзер төшендем. Үзем дә су тәменә сизгерләндем. Туган җир суы башка сулардан аермалы була икән шул.

**VIII. “Кеше... үзенең туган телен кагыйдәсез дә белер һәм һич тә ялгыш әйтмәс һәм хата сөйләмәс. Ләкин башка телне өйрәнәсе булсаң, ул вакытта үз телеңнең кагыйдәләрен белү бик кирәк. Чөнки кеше үзенең

**телен яхшы белмәсә, башка телгә төшенә алмас, тик бик озак вакытлардан соң гына аңа күнегә алыр," – дип әйтеп калдырган танылган мәгърифәтче галим Каюм Насыйри.** (Өзек хәзерге татар әдәби теленә тәрҗемәдә бирелде.)

**Сез ничек уйлыйсыз? Өзектәге фикергә үз мөнәсәбәтегезне белдереп, 15-20 җөмләдән торган бәйләнешле текст языгыз. Фикерегезне раслап, 2 дән ким булмаган дәлил китерегез.**

"Человек... может знать свой родной язык без правил и не ошибается. Но если хочешь изучать другой язык, то очень важно знать правила своего языка. Потому что, если человек не знает своего языка, он не сможет понять другого языка, только через много времени сможет привыкнуть к нему», - отметил известный просветитель Каюм Насыри.

Как вы думаете? Напишите сочинение-рассуждение из 15-20 предложений, выражая свое отношение к мысли отрывка. Приведите не менее 2 довода-примера. *(20 баллов)*

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| *I* | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеге гомуми. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил дә юк | 1 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| *II* | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |

| | | |
|---|---|---|
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br><br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br><br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br><br>**ләкин**<br><br>1 логик хатасы бар,<br><br>**һәм/яки**<br><br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br><br>**ләкин**<br><br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br><br>**һәм/яки**<br><br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br><br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br><br>**яки**<br><br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br><br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |

| | | |
|---|---|---|
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |

| | |
|---|---|
| **Язма эш өчен максималь балл** | **20** |